# Кошлар

Тулыландырылган икенче басма

Казан

Татарстан китап нәшрияты

2013

«Табигатькә сәяхәт» сериясе 2007 елдан нәшер ителә.

Серия авторы һәм автор-төзүчесе *Талия Шакирова*

Рәссамнары: *Ринат Хәсәншин, Алсу Тимергалина*

**Кошлар** / [серия авт. һәм авт.-төз. Т. Р. Шакирова ; рәссамнары : Р. Х. Хәсәншин, А. А. Тимергалина]. Тулыл. 2 нче басма. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2013. – 71 б. : рәс. б-н. — («Табигатькә сәяхәт» сериясе).

ISBN 978-5-298-02281-1

Китапта табигатебез бизәкләре булган кошлар хакында мәгълүмат бирелә, аларга багышланган шигырьләр, хикәяләр тәкъдим ителә. Җыентык урта һәм олы яшьтәге мәктәп балаларына һәм хайваннар дөньясы, табигать, экология белән кызыксынучы киң даирә укучыларга адреслана.

ISBN 978-5-298-02281-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2013

© Шакирова Т. Р., 2013

## Гомуми мәгълүмат

*(Кереш сүз урынына)*

*Кошлар Җир шарының барлык материкларында яши. Аларның якынча 40 отрядка берләшкән 9 мең чамасы төре бар.*

**БЕЛӘСЕҢМЕ?**

*Кошлар моннан 150 миллион еллар элек сөйрәлүче хай-ваннардан килеп чыккан.*

*Кошларның тәне каурый белән капланган. Каурый үзе* ***япма каурый*** *һәм* ***мамыкчыл каурыйдан*** *тора. Канатта урнашкан эре каурыйлар —* ***кагыну каурыйлары,***

*койрыктагы каурыйлар* ***руль каурыйлар*** *дип йөртелә. Кагыну каурыйлары кошларга очарга, манёврлар ясарга ярдәм итә. Каурыйлар кошларны сал-кыннан да саклый. Алар ел саен алы-шынып тора: бер өлеше коела, икенчеләре үсә.*
*Үрчү чорында кошлар күкәй сала. Ул известь кабык белән капланган була. Кайбер кошлар оя ясый, кайберләре күкәйләрен турыдан-туры җиргә, үләнгә, агач куышына яисә кыяларга сала. Икенче берләре (мәсәлән,* ***күке****) күкәйләрен башка кош ояларына да салырга мөмкин.* ***Ояда җитлегүче кошчыклар*** *ялангач, сукыр, ярдәмгә мохтаҗ булып,* ***күкәйдә җитлегүче кошчыклар*** *мамыклы, күрә торган булып туа-лар һәм, шунда ук яисә бераз вакыт узуга, әниләренә ияреп оча алалар.*
*Кошлар — җылы канлы хайваннар, аларның тән темпе-ратуралары үзгәрми. Баш мие һәм сизү органнары яхшы үскән, алар тавыш сигналлары ярдәмендә аралашалар.*

# Император пингвины
# Императорский пингвин

Император пингвины иң эре пингвин санала. Аның озынлыгы 135 сантиметр, авырлыгы 45 килограмм. Арткы очлыклары (аяклары) ярылы, алгылары канатка әверелгән һәм йөзгеч хезмәтен үти. Җирдә бик акрын, бер яктан икенче якка ава-түнә йөри, гәүдәсе арткы очлык-ларында вертикаль тора. Хәрәкәтләнмәгәндә, кой-рык-ның кыска каты каурыйларына таяна. Бозда һәм каты карда, корсакларына ятып, очлыклары белән этелеп шуа. Оча алмый. Ул су астында бик яхшы йөзә һәм 18 минутка кадәр тора ала.
Оясын Антарктида яр буе бозларында кора. Көз көне, бала чыгарыр вакыт җиткәч, ана пингвин бер күкәй сала. Күкәй өстендә ата пингвин утыра. Бу вакытта ул аша-мый, ябыга һәм 40 % тан артык авырлыгын югалта. Кошчык күкәйне тишеп чыккач, ояга ана пингвин кайта.
Ул балык, кальмар, вак кысласыманнар һ.б. белән туклана.

# Африка тәвә кошы
# Африканский страус

Африка тәвә кошы Көнчыгыш һәм Көньяк Африкада- яши. Аның биеклеге 2,7 метрга, авырлыгы 150 килограммга кадәр җитә. Муены озын, башы зур түгел, аяклары шулай ук озын, көчле, 2—3 бармаклы. Баш, муен һәм аякларында каурыйлары юк. Африка тәвә кошы очмый. Канатлары чагыштырмача зур, чит-ләре мамыкчыл. Күк-рәгендә мөгезчел сөяле бар. Ул аны имгәнүләрдән һәм кызган грунтта пешүдән саклый. Аф-рика тәвә кошы күчеп йөри. Бер ата кош 3—5 ана страустан торган төркемне йөртә.
Үрчү чорында ата кош комда чокыр (оя) ясый, ана кош-ларның һәрберсе шунда 7—9 күкәй сала. Күкәйләр өстендә чиратлап утыралар: көн-дез ана, төнлә ата кош. Утыру чоры 42 көн дәвам итә. Кошчыклар күрә торган, мамыклы булып туа. Аларны ата кош тәрбияли.
Ул вак кимерүчеләр, кәлтәләр, эре бөҗәкләр белән туклана.

# Америка тәвә кошы

# Американский страус

Америка тәвә кошының биеклеге 150 сан-тиметр, авырлыгы 40 килограмм. Ул — очмый торган кош. Ике төре бар: **гади** һәм **озын томшыклы Америка тәвә кошы**. Гади Америка тәвә кошы Бразилия һәм Аргентина, озын томшыклы Америка тәвә кошы Анд һәм Патагония далаларында таралган, зур булмаган көтү булып яшиләр.
Үрчү чорында ата кош 5—7 ана коштан торган көтүне йөртә. Ояны да ул ясый. Ана кошлар ояга 20—
40 күкәй сала. Күкәйләр өстендә ата кош утыра, ана кош көтүе башка ата кошлар янына китә һәм кошчыкларны тәр-бияләүдә катнашмый. Ояда ата кош төнлә һәм иртән генә утыра. Көндез оя өстендә канатларын җәеп басып тора. 40 тәүлектән соң күрә тор-ган, кара тимгелләр белән аралашкан сары төстәге нәни кошчыклар дөньяга килә.
Ул чебеннәр, суалчаннар, кәлтәләр, моллюсклар, яшь үсемлекләр һәм орлыклар белән туклана.

**БЕЛӘСЕҢМЕ?**

Америка тәвә кошының тешләре булмый.

# Гади казуар
# Обыкновенный казуар

Гади казуарның биеклеге 150—180 сантиметр, авырлыгы 60—80 килограмм. Алар тропик урманнарда пар-лашып яши. Үрчү чор-лары июль — август айларына туры килә. Ояны ата кош мүк һәм коелган яфраклардан җирдә ясый. Ояда, гадәттә, яшел төстәге 3—5 күкәй була. Күкәй өстендә ата кош утыра. Кошчыкларны да ул йөртә. Гади казуарның башында мөгез сыман үсентесе бар.
Ул үсемлек һәм кайбер вак хайваннар белән тук-лана.

# Эму
# Эму

Эмуның биеклеге 170—190 сантиметр чамасы, авырлыгы 45—55 килограмм. Страусларныкы кебек үк, тешләре юк. Ашказанындагы ризыкны ваклар өчен, ул таш, пыяла яисә тимер кисәкләрен йота. Суны бик сирәк һәм аз эчә. Йөзә белсә дә, күбрәк су өстендә утырып торырга ярата. Бик яхшы күрә һәм ишетә. Аякларында өчәр бармагы бар. Эму соры-көрән төстә була. Алар 4—6 эмудан тор-ган төркемнәргә берләшеп яшиләр, ачык урыннарда көтү-көтү булып йөриләр. Ата кош тигез урында яфраклар һәм ботаклардан оя ясый. Ана кош 7—8 күкәй сала. Күкәйләр өстендә 53—60 тәүлек дәвамында ата кош утыра. Бу вакытта ул ашамый һәм бик агрессив була. Кошчыклар туып кипшенгәннән соң ук ояларын ташлыйлар һәм эти-әниләре артыннан ияраләр.
Эму үсемлек һәм хайваннар белән туклана.

# Аккош
# Лебедь

Аккош борынгы заманнардан бирле матурлык, саф-лык, горурлык һәм нәфислек символы булып йөри. Ул — бакча һәм паркларга, сулыкларга ямь бирүче. Әлеге мәһабәт кош суда җиңел һәм тавышсыз йөзә. Аккош узган урында су, яктырып, перламутр төсенә кереп кала. Аның судагы һәр хәрәкәте кабатланмас нәфислек тудыра.
Аккош, яз көне җылы яклардан кайткач, оясын кеше керә алмаслык аулак күлләрдәге куе камышлар арасына ясый. Ул — искиткеч сизгер һәм сак кош.
Аккошның авырлыгы 6—13 килограммга хәтле җитә. Алар көтү булып яшәми, гадәттә, парлашып яши. Үрчү чорын-да ана кош 3—5 күкәй сала. Күкәйләр өстендә ана кош утыра, ата кош аның янәшәсендә йөри. Күкәй өстендә утыру чоры 30—40 тәүлек тәшкил итә. Нәни кошчыклар, кипше-нүгә, әти-әниләренә иярә алалар.
Ул азыкны сай сулык төбеннән чумып таба. Кысласыманнар, моллюсклар, вак балыклар, үсемлекләр белән тук-лана.
**БЕЛӘСЕҢМЕ?**

Аккошларның кара төстәгеләре дә була.

Аккош — сайрамый торган кош. Алар кыйгакларга (кара аккош) яки ысылдарга гына мөмкин.

# Язгы балкыш

*Айдар Җамалиев*

Язын күлләрдә
Искиткеч балкыш.
Җылы яклардан
Кайткан бит аккош.

Ул сайрамый да,
Тик йөзә бирә.
Шулчак күңелгә
Нәфислек керә.

Көчле булса да,
Мохтаҗ яклауга.
Их, аккошларны
Ничек сакларга?!

# Аккош

*Гарәфи Хәсәнов*

Һәр тарафта тынгысыз гөрләвекләр челтери. Инде су чит-ләре боздан арчылган. Ләкин әле яр буйларында, агач, куак төпләрендә ап-ак кар ята. Кичләрен, кояш баер алдыннан, кар өсләре алсу төскә керә. Шулчак күктә алсу күл өстендә алсу кошлар төркеме күренә... Озын зифа муеннары алга сузылган, кыска, көчле аяклары — артка...

Киң канатларын бик салмак селтиләр. Алар ерак юллар кичеп тәмам арыганнар, хәлдән тайганнар. Син аларны кызганып куясың, камышлы күлгә төшеп, бераз ял итүләрен телисең. Ләкин алар баш очыннан гына узып китә. Хәер, арадан бер пары, иптәшләреннән аерылып, түбәнрәк төшә түгелме соң?.. Әйе, әйе!.. Димәк, бу күл — шушы пар аккошның туган төбәге, Аккош күле! Бу күлгә алар, бары тик алар гына хуҗа. Башкалары шуны белеп китеп баралар икән.
Төшеп җитәрәк аккошлар муеннарын аска бөкteләр, гәүдәләрен турайтып, канатларын җилгә каршы җилпи баш-ладылар, аякларын тырпайтып, алга суздылар. Шул рәвешчә саллы гәүдәләренә «тормоз» ясап, су өстенә төшеп утырдылар...
Алсу күл өстендә алсу кошлар йөзә. Күкрәкләре суга шактый тирән кергән, гәүдә-койрык ягы, кыйгачланып, өскә күтәрелгән, ак муеннары мәһабәт бөгелеп, зур сары том-шык-лары су көзгесенә үк иелгән.
Менә алар икесе ике якка аерылып китәләр дә, кинәт борылып, бер-берсенә каршы килә башлыйлар. Бераздан, бөтенләй якынлашып, томшыкка томшык килеп теріләләр, гүя исән-имин туган җиргә кайту шатлыгы белән тәбрикләшәләр. Ул да булмый, томшыкларын зәңгәр күккә сузып, көмеш быргы авазлары чыгарып кычкырырга тотыналар... Бу — аларның язгы җыры, бу — аларның туй башлап җибәрү турында аваз салулары...
Син аларның табигатькә, гүзәллеккә мәдхия җырлаула-рына сокланып, сак кына күл читенә якынлашасың. Ә алар игътибар да итми. Ләкин бу беренче карашка гына шулай тоела. Әгәр дә син, әрсезләнеп китеп, бу тирәдә артык бутал-саң, еш килеп, тавышланып йөрсәң, аккошлардан җилләр исәчәк. Бу күлгә хәтта алдагы елларда да әйләнеп кайтмаячак-лар...
Аккош күле! Кайда гына юк андый исемдәге күлләр?! Ләкин хәзер күбесенең исеме бар, җисеме юк. Аларны әрсез бәндәләр биздергән, шуңа күрә аккошлар безнең якларда бик аз калган.
Сез шуны һәрчак исегездә тотыгыз: аккошлар — сак кош-лар. Алар тынычлык яраталар, саф һава, көмештәй саф су яраталар.

# Кыр казы

*Гарәфи Хәсәнов*

Кыш бабайның ак туны тәмам искерде, ала-кола булып калды. Иңкү аланнарга җәелгән кар суы яз кояшында көмеш көзгедәй балкып ята. Ә кыр казлары ерак сәяхәттән кайтып та килә. Алар, өчпочмаклы тигез сафларга тезелеп, үзләре туып үскән тымызык күлләрне, кеше йөрми торган тын аланнарны эзләп очалар.
Кайтып төшү белән, әнкә каз эшкә тотына. Су уртасында калган берәр калкурак урынга, чытырмандай куаклар төбенә оя кора башлый. Ул аны төрле чыбык-чабыктан, корыган камышлардан әмәлли. Түшеннән йолкып, мамык-йоннарын да түши. Шунда дистәгә якын эре яшькелт йомыркалар сала. Аннары, кайнар шәрә түше белән булачак бибиләрен җы-лытып, айга якын урыныннан купмый утыра. Ә этkә каз, төнне көнгә ялгап, оя тирәсендә сакта тора. Әгәр якын-тирәдә берәр хәтәр җәнлек яки ау эте күренсә, «гак» дип, бу хакта хәбәр сала. Сак бул, тыныңны чыгарма, янәсе!
Менә беркөнне, бер үк сәгатьтә диярлек, әллә ничә йомырка борынлап, әллә ничә биби-бәбкә борын төртә. Әнкә каз, шатлыктан ни кыланганын белмичә, уңга-сулга боргалана, «га-га-га» дип, йомшак тавыш белән үзенең нәниләренә дәшә, аларны назлый, иркәли.

Әниләренең җылы канаты астында бераз кипшенгәч, йоп-йом-шак хәтфә йомгаклар, тәгәрәшеп, суга төшәләр дә йөзеп китәләр. Ә эткә каз, аларны хәвеф-хәтәрдән саклап, иң арт-тан бара.

# Кыр үрдәге

*Гарәфи Хәсәнов*

Болын-тугайлар җәйгә әзерләнә. Бил тиңентен суда кал-ган куаклар бөртек-бөртек бөреләргә бизәлә, тал-тирәкләр үзләренең судагы шәүләсенә карап купшылана.
Бу гүзәллеккә сокланып, очар кошлар, юлдан тук-тап, барасы җирләрен оныталар. Кояш нуры балкыган күл өстенә төшеп, аның салкын суын эчәләр.
Әнә күл уртасында бер пар кыр үрдәге мәш килә. Эткә үрдәк кинәт-кинәт яшькелт башын суга манчып-манчып ала. Аннары горур кыяфәт белән бер читкә йөзеп китә дә, борылып, койры-гына утыра, әйтерсең шулай төз басып, юлдашына үзенең буй-сынын күрсәтә. Йә җәһәт кенә суга чумып чыга, зәңгәрсу муен каурыйларын тырпайта, баш каурыйлары яшел-ләнеп ут яна. Бу инде эткә үрдәкнең язгы уены. Ә әнкә үр-дәк шундый тыйнак, шундый салмак хәрәкәтле. Ул тегенең ниләр кыланганын читтән генә күзәтә. Ара-тирә сызгыртып, кагынып куя. Аннары, капыл гына су өстеннән күтәрелеп, каядыр очып китә. Эткә үрдәк тә аннан калышмый. Димәк, алар кайдадыр оя корганнар яки калку утраудагы чытырманлыкта әзер иске оя тапканнар. Әнкә кош ул ояга, йомшак мамык түшәп, йомыркалар сала. Эткә үрдәк ерак күлгә оча, ай буе куе камышлар арасыннан чыкмый, сазда казынып ята. Чөнки бу вакытта аның канат каурыйлары коела, яңалары үсә. Кая карама — шунда өтек үрдәкләр. Бер айдан алар һәммәсе яңа кием кияр, тик бу киемнәре яшелле-зәңгәрле түгел, әнкә үрдәкләрнеке кебек, гап-гади булыр. Кешеләр әйтмешли, матурлык туйда гына кирәк!
Бәбкәләр чыгып, азрак үсә төшкәч, күлгә юнәләләр, тезелешеп, әнкәләре артыннан йөзеп китәләр. Эткәләрен дә беренче кат шунда күрәләр. Ләкин ул боларны бөтенләй танымый. Хәтта әнкәләрен дә онытып өлгергән була. Хәер, аның үзен дә танырлык түгел, чөнки кием-салымы бөтенләй башка. Бе-раздан аңа тагын бизәкле каурыйлар үсәчәк, һәм ул үзенә икенче пар табачак. Ә бәбкәләр җәй буе әниләре янында яшәп чыныгачаклар.

# Затлы гриф
# Королевский гриф

Затлы гриф Көньяк Мексика белән Төньяк Аргентина арасындагы территориядә тарал-ган. Ул тро-пик урманнарда һәм урманлы саванналарда яши. Авырлыгы 4 килограммга кадәр җитә. Затлы матур каурыйлары аклы-каралы төстә, башын төрле төсләрдәге чыгынтылар бизи. Яшь гриф көрән төстә була, бары 4 елдан соң гына каурыйларын аклы-каралыга үзгәртә. Ул үләксә белән туклана. Башка кошлардан аермалы буларак, исне бик яхшы сизә. Шунлыктан үлән ара-сында күренмичә яткан, инде таркала башлаган хайван үләксәләрен дә тиз таба. Затлы гриф шулай ук башка кошларның «бан-кет»ында да чакырылмаган кунак буларак катнашырга мөмкин. Көчле томшыклы әлеге кошны «банкет» хуҗалары бер-сүзсез кабул итәләр.
Ул вак кошлар белән дә туклана, ләкин ул табышын очып барган җиреннән эләктерә алмый.

Затлы гриф оя кормый. Ана гриф бердәнбер күкәен черегән агач куышына сала. Күкәй өстендә ата һәм ана гриф чиратлап утыралар.

# Киң авызлы тилгән
# Широкоротый коршун

Киң авызлы тилгәннәрнең күбесе җылы якларда утрак тормыш белән яши. Салкын якларда яшәүче тилгәннәр күчмә тормыш алып баралар: көз көне, салкыннан куркып, Үзәк һәм Көньяк Европага күченәләр.
Ул оясын урманда яисә әрәмәлекләрдә куаклар арасына кора. Башка ерткыч кош-лардан аермалы буларак, аның канат-лары һәм койрыклары киң, кыска. Ул әкрен оча. Авыр-лыгы 500—1000 грамм.
Киң авызлы тилгән — тыныч табигатьле кош, хәтта ялкау булып күренергә дә мөмкин. Дошманын ачык һавада «асы-лынып» торган килеш күзәтә. Кыя яки биек агач башында торaташ кебек катып калган һәм очлы күзләре белән табышын сагалаган тилгәннәрне дә еш очратырга мөмкин. Киң авызлы тилгән биектән дә яхшы күрә. Оясыннан борыны гына күренеп торган тычкан яки күсене дә шунда ук абайлап ала. Салмак, ләкин нәкъ нок-тасына туры китереп очкан тилгән тырнагына кабуын тыч-каннар үзләре дә сизми кала.

# Тилгән

*Гарәфи Хәсәнов*

Су язын ялгыз тилгән кайтара. Шул ялгыз тилгән аның хәбәрчесе булып санала. Яктылык язы китәр юлга кузгала, ялгыз тилгән авыл өстендә әйләнә. Кар эри, гөрләвекләр чел-тери... Менә шул хәлне әйтеп җилпенә дә инде тилгән. Җилпенми, күктә йөзә кебек күренә. Чөнки ул, канатын җәеп, һава агымына бирелгән. Авылның һәр малае күрә тилгәнне. Күрә һәм сөрән салып кычкыра:
— Тилгән, тилгән, бәбкә алырга килгән!
Ә бәбкә күкәй-өйчегендә утыра. Ул әле бары борын-лар-га гына җыена. Юкны бар итеп ничек алсын икән бу тилгән?
Менә берзаман бүтән тилгәннәр дә күренә. Ялгыз да, икәү-өчәү булып та — менә ни рәвешле очып кайталар бу кошлар. Кайткан бере авыл тирәсендә әйләнә. Кеше бар җирдә ерткыч тилгәннәр дә бар. Көнозын күктән төшүне белми тилгәннәр. Табышны күктә килеш күзәтәләр. Ә җирдә кара карга эзләнә. Ул да көнозын авыл тирәсендә мәш килә. Кеше бар җирдә кара каргалар да бар. Тилгән ул кара карга кебек бу яктан. Әле тагын бер яктан охшыйлар икән кара каргага: көндез һәр тилгән ялгыз-йолгыз әйләнә, ә кичен ишле көтүгә берләшә, бердәм булып, дәррәү кузгала. Үзләре ерткыч кошлар, үзләре бер урынга, бер җиргә юнәләләр. Димәк, бер җирдә тату яшиләр. Тик кая, нинди җиргә оча икән соң алар? Үзең кич саен чиксез тугайны гизәсең, үзең шушы сорауны бирәсең. Түзми-сең, очкан якларына, яр буйлап урман авызына атлыйсың.
Урман бер яктан көчле агымлы суга елмая, икенче яктан тугай киңлегенә күз сала. Тугай да әле яшел эскәтерен җәймәгән, урман да әле кучкыл шәрәлеген җуймаган. Үләннәр, бөреләр әле йокысыннан гына уяна. Шәрә һәм сирәк агачлы ул яр буе. Менә ни өчен зуп-зур ояларны күрәсең. Яр буе кошлар шәһәренә охшаган. Зуп-зур оялар һәммәсе бер үк тирәдә. Гүя дус кошлар — кара каргалар корганнар. Әмма һәр оя япьле

ботакка урнашкан, һәр оя кәүсәгә ышыкланган. Бары шул яктан безгә яхшы таныш ояларга охшамый. Әле нишләптер оя ияләре күренми. Тукта, зур соры кошлар канат җилпемичә төштеләр. Ләкин иске ояларын читләделәр бу кошлар: берьюлы бер үк имәнгә дә төштеләр, аның оп-озын корыган ботагын да сардылар. Өстән әйтерсең соры пиджак кигәннәр, астан әйтерсең саргылт күлмәкләре бүлтәеп тора. Башлары шактый аксыл, ә сары күзләре... Нәкъ тавык карчыгасы күзләре! Томшык һәм тырнаклары кара ыргакларга охшаган — ерт-кыч икәннәрен күрсәтә. Ә ерткыч кошлар санап исәбенә чыкмаслык. Көн яктысында кырык төре оча, һәрберсе... «тил-гән» дип дан алган. Әйе, «тилгән» дип, тилгән түгеленә дә әйтәләр. Тилгәнме, әллә бүтән кошмы гаепле, әмма авылда тавык-фәлән югалса, аны, әлбәттә, тилгән урлады, дип әйтәләр. Ак эт бәласе кара эткә эләгә. Ә аның нәрсә ашаганын уйласаң... Хәер, ни ашаганын үзе күрсәтер әле берәр вакыт. Һәм бәйнә-бәй-нә әйтелер дә бу хакта. Хәзер тик сары күзләренә карый-сың. Шул сары күзләрендә кызгылт чаткы уйный, анда ник кенә ерткыч усаллык чагылсын! Ләкин бу күзләр очкан вакытында күренми. Ә таныйм дигәндә... Әйе, андыйга маңгай күзен ачу да бик җиткән. Тилгәннең тилгән икәнлеген койрыгы күрсәтә: очканда уемланып тора аның койрыгы. Тилгәннең тилгән икәнлеген озын канатлары күрсәтә: киң булып, озын булып койрыгына ук барып җитә.
Юл алды су язы. Үз урынын күркәм энесенә калдырды. Инде май матур тулы хуҗа булып утырды. Утырды, туган якны бизәде. Аны «чәчәкләр язы» дип юкка гына әйтмиләр. Инде яр буе шомырт чәчәкләре белән, хуш исле, ап-ак шомырт болытлары белән бизәлде. Урман мең төрле сайрар кошкайлары белән тылсымлый. Инде сандугач көнне төнгә авыштырып чутылдый: үзе су буендагы куе ботаклыкка урнашкан, үзе әйтерсең бака халкы белән ярыша. Менә ни өчен килмәс җирдән киләсең бу урманга. Өй барын, тамак ягын онытасың андый чакта.
Тилгәннәр очу-йөзүне үк ташлаганнар, кеше тирәсен-нән бизгәннәр. Инде ник берсе авыл өстен әйләнсен... Мөгаен, урман тылсымына бирелгәннәрдер яисә чәчәк болытыннан баш-лары ук әйләнгәндер. Юк, алар иске ояларын күргәннәр! Су язы үтте-китте дигәндә... бары шул чакта иске ояларын күр-гән-нәр, бары шул чакта төзү-төзәтү хәстәренә керешкәннәр.
Ә инде чәчәкләр язы килгәч... син күр дә мин күр, һәр оя аксыл күкәйле! Күкәйләр әйтерсең санап салынган. Шушы санаулы аксыл күкәйләре өстендә әнкә тилгән утыра. Гәүдәгә дә зуррак әнкә тилгән, көчкә-куәткә дә уздыра, һәм ул, оя корып, ялгыз башы утыра. Көчле дә, шактый зуррак та бул-ган-га, бернинди дошманга да бирешми. Ә эткә кошка кил-гәндә... Аның үз эше үзенә җитәрлек: ауга очудан туктамый — үзен һәм әнкә дустын туйдыра.
Ләкин эткә кош сайрау, уйнаудан да баш тартмый. Менә ни өчен ул иртә уянучан. Төн әле көнгә генә тоташа, әле чык тамчылары энҗе бөртегедәй җемелди. Шунда әйтерсең төртеп уятканнар бу кошны: утырган ботагында сары күзләрен дә зур ача, як-якка озын канатын да киң җәя. Анысы — уянгач киере-леп алуы. Аннары бер-бер артлы сары аякларын сузгалый, шул рәвешле ыргак тырнаклы сары аякларын яза ул. Бары шун-нан соң гына аваз сала — оя тибүчене уята. Ул аңа башын арт-ка ташлап кычкыра. Фәкать пары уянгач кына, ботак-куначасын калдыра. Әмма ник бер киң түгәрәк ясасын — бары оя өстен күзләү белән генә чикләнә. Анда бертөрле куркыныч та күрмәсә, бары шул чагында күңел тынычлыгы таба һәм ерак-еракларга очарга батырчылык итә. Ул хәзер елга өстен әйләнер, анда балык «каптырыр» яисә, бака тотып, ачлык кортын басар дип көтәсең. Ләкин каптыру яки тоту өчен озаклап күзләргә кирәк, ә аның түзәр әмәле калмаган. Менә ни өчен чиксез тугайга ук атыла. Ләкин анда да өскә күтәрелми җилпенә. Әһә, андагы вак-вак балыкларны күргән дә шул үлгән балыкларны чүпләү ягын чамалый. Зуррагын тапкач, таныш оясына

ашкына. Тик әнкә кошкайның кече теленә дә йокмый аның тапканы. Нишләсен, әткә тилгән күршеләре челән халкы янына юл ала. Ә алар «балык тоту» белән мәшгуль. Тездән су ерып, балык аулыйлар челәннәр. Әлбәттә, шактый эресе дә эләгә, аны челән йота алмый аптырый. Бусы, әлбәттә, әткә кошка эләгә. Шуны бүләккә әнкә кошка кайтара да тилгән, бары шуннан соң йөзү-җилпенүе башлана. Башта ул тап-тар түгәрәкләр ясау белән чикләнә. Тик ул түгәрәкләр киңәя баралар, тилгән торган саен биеккәрәк юл ала. Аңа чак сизелерлек һава агымы да бик җиткән. Менә ул ни өчен озын канатларын җәйгән дә аларны җилпү-кагуны ук оныткан. Шулай аз-азлап өскә күтәрелә бу кошкай. Инде син күр дә мин күр, нәни ноктага ук әверелә. Шунда күз чагылдырып карыйсың да сокланасың тилгәнгә. Ләкин бу нәни нокта төшә, зурая бара — тилгән ни ара озын канатларын кушырган һәм таш булып аска атылган?! Әмма төште, инде тәмам җиргә иңде дигәндә... кинәт кенә тукталып та өлгерә. Ашыкмый гына зуп-зур түгәрәкләр ясый һәм яңа-дан өскә күтәрелә. Ай-һай, ничек арымый дип аптырыйсың. Менә ул тагын нәни ноктага әйләнә. Ә тагын бераздан... Әйе, ул инде биек күктән төшәргә дә өлгергән, тагын бер тапкыр катнаш урман өстен айкау белән мавыга. Ә бераздан... әткә кошкай ботак-куначасына утыра.
Арыгандыр, бүтән кузгалмас дисең. Ә тил-гән яңадан аткан укка әйләнә. Туп-туры өскә күтәрелә бу юлы. Димәк, уңай
һава агы-мын сайлаган! Күктә чак сизелерлек кара ноктага әверелгәч, янә таш булып аска томырыла һәм төшеп җитәрәк... шат-лыктан матур итеп сызгырырга тотына. Аңа әнкә кош күңелле сыз-гыру белән җавап кайтара. Аннары түзми, ояны калдыра — дустын күктә каршылый. Шунда инде әнкә дус-каена очу осталыгын күрсәтә әткә тилгән. Ул шуның белән дустына ләззәт бирә. Башта, җилпенеп, аның тирәсендә әйләнә, аннары, канат какмый гына, биек-биеккә ургыла, нәни ноктачыкка әверелә. Ә бераздан ул әнкә дусты янына да төшеп җитә һәм гүя, әнкәсе, бар, очып кил, күңел ач бераз, дип, дустын җибәрә дә, озын канатларын киң җәеп, җылы күкәйләр өстенә үзе утыра.
Ләкин кояш та сиздермичә тәгәрәпме-тәгәри. Башта аз-азлап күкнең түбәсенә менә, аннары бату тарафына юнәлә. Кояш аз-азлап таудан төшә кебек бу чакта. Нәкъ өйлә узгач, әткә кош ауга кузгала. Ләкин һәр көнне очып туйгач кына кузгала. Яки дускае өчен оя типкәч кенә. Нәни тилгәннәр чыккач та, әле ташка тамга салган кебек итә ул: башта һәр көн-не бөтен күкне гизә, бары шуннан соң гына азык ягын кай-гыр-та: кырлар өстенә күтәрелә. Үзе кыр өсләп шундый биектә әйләнә, үзе кырдагы нәни тычканны күзли. Күрдеме — таш күк өстенә дә атыла. Көнгә дистәдән артык тычканны юк итә. Ә инде кыр тычканнары күзенә чалынмаса, эре бөҗәкләрдән дә баш тартмый. Көнгә ничәмә-ничә йөз башак коңгызларын юк итә. Ләкин бөҗәк аның кече теленә дә йокмый. Шуңа әрсез әрләнне өстәргә туры килә, һәм ахыр чиктә үзе дә, әнкә дускае да тук була. Тилгән — йомраннарның да дошманы. Аларны аулаганда, тилгән өлгерлек күрсәтә, кирәксә, шун-дый сабыр да була ала, көтеп тә «утыра». Әйтик, биектә берәр йомранны күрә дә таш булып аның өстенә атыла. Ә тегесе, моның төшкәнен шәүләсеннән сизеп, тизрәк табан ялтырату ягын карый.
«Тилгән, тилгән, бәбкә алырга килгән...» дигән таныш такмак шул чагында инде бөтен дөреслеге белән яңгырый. Чөнки ул яңадан авыл өстендә тулгана башлый. Иң әүвәл кайту белән күренсә, хәзер китәр вакыты җиткәндә күренә. Җай чыкса, тавык-чебештән авыз итүдән дә тайчанмый. Ләкин файдасы иткән зарарыннан күп мәртәбәләр артык. Менә ни өчен гафу ителә дә бу тилгән.

# Ябалак

# Сова

Ябалак — төнге ерткыч кош. Ул, нигездә, агачлы урыннарда (урманнарда, паркларда һ. б. урыннарда) һәм кайвакыт чормаларда яши. Ябалакның да, көндезге ерт-кычларныкы кебек, том-шыгы ыргак сыман бөгелгән, бармаклары озын һәм көчле, тырнаклары шулай ук бөгел-гән була. Тәнен куе, ләкин көп-шәк каурый япмасы каплаган. Ул тавышсыз оча. Каурыйлары соры-көрән төстә. Күзләре зур, караңгыда күрә. Бик яхшы ишетә. Барлык кошлар арасында бары ябалакның гына колак яфраклары бар. Ауга төнлә чыга. Табышын тавышы буенча таба. Тычкан, куян, тиен, керпе һәм вак кошлар белән туклана.

Ябалакларның күбесе утрак тормыш белән яши. Россиядә яши торган **зур колаклы ябалак** һәм кайбер **Америка ябалаклары** — күчмә ябалаклар.

Ябалаклар гомер буе парлашып яши. Алар оя ясамый. Аулак урыннарны, агач куышын, кыя ярыкларын яраталар, эре кошлар ташлаган чит ояларга да урнашалар, чокырлы урыннарны да үз итәләр. Җирдә, бернәрсә дә түшәмичә, ана ябалак 1—11 күкәй сала. Күкәй өстендә ана кош утыра. Күкәйдә кошчыклар 24—35 тәүлек үсә. Кошчыклар мамыклы, сукыр, чукрак булып туа, озак вакыт җылытуны һәм аша-туны сорый.

Ябалак — авыл хуҗалыгы өчен файдалы кош. Аны сак-ларга кирәк.

# Йорт ябалагы

*Гарәфи Хәсәнов*

Бер пар кош. Шундый дус, шундый турылыклы бер пар кош. Алар бары бер-берсен генә белә, җәен дә, кышын да сайлаганын ташламый. Бу яктан бездәге барлык ябалаклар кебек. Ләкин бүтәннәр гәүдәләре белән алдыра, ә болары биг-рәк кечкенә. Теге зур ябалаклар калын урманнарда яши, болары — кыр, өйләр тирәсендә. Алар кырдагы сазлы урманга да канәгать. Авылда исә абзар-кура тирәсенә урнашалар, аулак почмакларда яшиләр. Йорт ябалаклары дип белми әйтмәгәннәрдер инде.

Көндез берсе-бер кеше күзенә чалынмый. Бары кич төш-кәч, тамак ягын кайгыртып, бер кош икенче кошка: «Ауга кузгалыйк», — дип сүз куша. «Бу-бу», — дип, калын тавыш белән әйтә ул. Гүя, бу инде ауга чыгар вакыт, ди. Әле еш кына: «Күвит-күвит», — дип тә эндәшә... «Күп бит» дип әйтә кебек. Имеш, ауларлык җим дә бик күп була, кич төшкәч. Алар — коңгыз һәм әкәм-төкәмнәрнең дошманы. Бакча һәм кырларда, бөтен зарарларын белгәндәй, төнозын күпләп кыралар аларны. Әмма төп азыклары — тычканнар. Бакча һәм кырларда да, өйдә һәм абзар тирәсендә дә тоталар тычканнарны. Кешегә бик ышаналар, хәтта кулга ияләшкән чаклары да булгалый. Алай булса, мәче-фәләнең дә кирәкми...

Әнкә кош дүрт-биш күкәе өстендә утыра; чуп-чуар кау-рый-йонын сыйпасаң да кузгалмый. Оядан ап-ак йомырка-сын алсаң да ачуланмый: алгач кире куясыңны белә шул ул...

# Йорт чыпчыгы

# Домовой воробей

Йорт чыпчыклары, нигездә, тропикларда, җылы як-ларда яши. Иң күпләп яшәгән урыннары — Африка илләре. Бу илләрдә яши торган йорт чыпчыклары утрак тормыш алып баралар, бик сирәкләре генә күчеп йөри. Урта пояста, аерым алганда, безнең якларда яши тор-ган йорт чып-чыкларын — күчмә кошларны очратырга мөм-кин. Әлеге кошлар төркем-төркем булып яшиләр һәм аларны торак пунктлар тирәсендәге һәр җирдә: басу-кыр-лар-да да, фермаларда һәм шәһәр урамнарында да очратырга мөмкин. Халык күпләп яши торган шаулы шәһәр урамнарын һәм бистәләрне йорт чыпчыклары бигрәк тә үз итә. Аларга шәһәр торак пунктлары тирәсендә азык һәм оя табу да, ерткычлардан саклану мөмкинлеге дә бар. Шәһәр урамнарын кешеләрнең юлдашына әйләнгән әлеге кошлардан башка күз алдына да китерүе кыен.

Ата йорт чыпчыгын, соргылт бүреге һәм күкрәгендәге кара күкрәкчәсеннән, ана йорт чыпчыгын соргылт-көрән түсе буенча танып була. Алар түбә кыекларына, стена ярыкла-рына оялыйлар яисә куак, агач араларына куполга охшаган зур-зур оялар коралар. Оялары башка бер кош оясына да охшамаган. Ул үзгә бер конструкцияне — тукып ясалган ояны хәтер-ләтә.

Барлык чыпчык балалары кебек, йорт чыпчыгының кош-чыклары да ялангач, сукыр, ярдәмгә мохтаҗ булып туа. Беренче көннәрдә ата-аналары балаларын бик нык кайгырта: кошчыкларны җылыта, ояны чистартып тора. Балаларын башта вак бөҗәкләр һәм аларның личинкалары, суалчаннар белән тукландыра, соңрак эре коңгызлар, бөртекле культураларның орлыклары белән туендыра. Олы кошлар үзләре орлыклар, җиләк-җимеш, иген бөртекләре, азык калдыклары һәм бөҗәкләр белән туклана. Шул рәвешле йорт чыпчыклары зарарлы бөҗәкләрне юк итеп кенә түгел, ә чүп үләннәренең орлыкларын чүпләп тә зур файда китерә.

# Су чыпчыгы

*Гарәфи Хәсәнов*

Ап-ак түшле һәм ак муенлы, кызгылт башлы һәм кызгылт корсаклы, күгелҗем-зәңгәр сыртлы ул су чыпчыгы. Шундый сак, шундый сизгер кош булса да, ару-талуны һич белми. Аңа еракта кинәт пәйда булуың да бик җитә. Күрә һәм менә нәрсә дип әйтә кебек тоела: «Койрыгым, канатым да кып-кыска, түгәрәкләнеп торалар, әмма мин шулар белән җитез очарга да бик оста». Аны ай күрә, кояш күпсенә — түбән һәм тиз-тиз очып күздән дә югала. Әгәр аңа якынаю бәхетенә ирешсәң... Бары шул чакта гына тыйнак кыяфәтен күрсәтә. Бары шул чакта гына матур челтерәве белән каршылый. Агым су кебек челтерәпме-челтери.

Су чыпчыгының калын, җылы йон-каурыйлары һич тә тырпаеп тормас, тәненә сыланып, гәүдәсен искиткеч ыспай, җыйнак һәм күркәм итәр. Чын мәгънәсендә су кошы ул! Гадәттә, ул суның шактый сай, ләкин кызу агымлы, ташлы урынын сайлый, шунда яши. Су тирәсендә яшәүче бүтән кош-лар (чәберчек, чумгалак һ. б.) кебек үк, ул да озын һәм нык сыйраклы була. Бармак очлары сәер генә икегә аерылып тора, ә ул араны яры каплаган, тырнаклары гаҗәеп озын һәм кәкре. Шунлыктан ул шома ташлар өстеннән рәхәтләнеп, бер дә чыланмыйча йөри ала. Су чыпчыгы дип белми әйтмиләр инде. Үзе бәләкәй — бары чыпчык сыңары, үзе саф сулы тынмас шарлавыкны ярата. Яки инеш, кизләү тирәләрен үз күрә. Саф су һәм көчле агым булсын аңа! Гүя ул суның челтерәвен откан һәм җыр отуда мәшһүр сыерчык белән ярышырга уйлаган. Аны су

сыерчыгы дип тә, су баркылдыгы дип тә атыйлар. Көн аяз булса, сайравыннан туктамый, әгәр җәйге көн кашын-күзен җимерсә, яр өстендәге бөҗәкләрне чүпли, яр буйлап йөгерепме-йөгерә. Суга төшүдән дә баш тартмый. Нәни койрыгын уйнаткалап, су эчендәге шома ташлардан да йөгерә. Ара-тирә кыска канатларын җилпеп, таштан ташка сикерә. Дулкын да кага, эре тамчылар да чәчри, ә ул су бөҗәкләрен чүпли. Гүя шул шома ташларда да уйнау-шаярудан туктамый, тели икән, суның төбенә үк төшә. Үзе — кош, үзе — балык дип әйтерсең! Тиз йөрергә аңа кыска канатлары булыша. Шуңа ул суда очкан сыман тоела. Аның борын һәм колак тишекләре элпә-япкычлы, әнә шул элпә суны керттерми саклый. Суда шулай йөри торгач, көчле шарлавыкка эләгә. Шарлавык текә һәм ташлы ярдан төшә дә җәй һәм кыш буе шашып-күбекләнеп ага. Менә шундый хәтәр җиргә килеп эләгә бу кошкай. Аннан ул күпме көтсәң дә күренми. Шуңа син, харап булды, дип әйтәсең, сагыш-кайгыга ук төшәсең. Ләкин сак кошкай төлке шулпасы эчкән икән ич: текә һәм ташлы ярның астына... оя корган икән ич! Оясын ул зур да, түгәрәк тә, җайлы да итеп ясаган. Шарлавык астына ләтчәдәй җәнлекләр дә баш тыкмый, ерткычның оча торганы да эләкми. Әнә ничек җил-яңгыр тидерми үстерә икән ул балаларын! Шуларны күрү, җим бирү өчен судан кергән икән бу кошчык. Кай арада оясыннан чыгып, бөҗәкләрне эзләп тапкан диген. Инде тагын бер тапкыр җиңел сулыйсың, аны күргәч...
Аңа хәтта кышын да көчле агым булсын һәм шул көчле агым зәмһәрир салкында да туңмасын. Ул кыш буе суга төшүдән баш тартмый. Чөнки бар азыгын су төбеннән таба. Вак балыкларны тотып, су өстенә чыкканда, тәмам танымаслык була: куе йон-каурыйлары салкын нурлардан җемелди. Кошка да, зат-лы таш-чыкка да охшый ул. Әле кош-ташчык сайрап куярга да күп сорамый. Әйе, бар тирә-юньне ап-ак кар каплаган, һәм кыш-кы салкын гармунсыз биетә, ә ул агым су кебек челтерәпме-челтери. Аның шундый шат, шундый батыр кошчык булуына шаккатып хәйран каласың...

# Кызылтүш
# Зяблик

Кызылтүш — бик матур итеп сайрый торган кош. Аның чут-чут килеп яңгыратып сайравын урман аланында да, шәһәр паркында да, бакчада да ишетергә мөмкин.
Язын кызылтүшләр ояларын пар-лашып ясыйлар. Бу чорда алар сугыш чукмарларына әйләнәләр: үз тирәләреннән башка кызылтүшләрне куып җибәрәләр. Ояларын, кәр-зингә охшатып, мүктән, нәзек чыбык-лардан, үләннәрдән бик пөхтә итеп ясыйлар. Кызылтүшләр-нең агачка яки куакка тырышып яшерелгән ояларын тәҗрибәле күз генә аера ала.
Кызылтүшләрнең балалары күп ашыйлар һәм бер-тук-таусыз ашарга сорап торалар. Шуңа күрә, бик күп азык табарга кирәк булганлыктан, аларга җәй көне мәшәкать арта. Тырыш кызылтүшләр җәй буе урманнарны, бакчаларны корткыч бөҗәкләрдән чистарталар.
Җәй ахырларында, балалары үсеп җиткәч, кызылтүшләр көтү-көтү булып көньякка очып китәләр.

**ИГЪТИБАР!**

Кызылтүш, оясына кемнең дә булса кагылганын белсә, аны шунда ук ташлап китә.

# Кызылтүшләр

*Ленар Шәех*

Кызылтүшләр чут-чут сайрый,
Яңгыратып урманны.
Шунда берсе күреп алды
Минем карап торганны.

«Без көньякка китәбез!» — дип
Юаналармы әллә?
Кызылтүшләр очып китте –
Оялалармы әллә?..

Белеп торам: оялдылар,
Хәтта мин дә оялдым.
Кызыл түшләренә карап,
Моңаеп карап калдым.

# Карлыгач
# Ласточка

Карлыгачларны авыл һәм шәһәрләрдә дә, елга, яр буй-ларында да очратырга мөмкин. Авылда яисә шәһәрдә яшәүче карлыгачлар ояларын, балчык кисәкләрен җилемле селәгәй-ләре белән ябыштырып, өй кыекларында, тәрәзә өсләрендә коралар; яр карлыгачлары исә томшыклары һәм тәпиләре белән биек текә ярларны тишеп ясыйлар. Карлыгач аксыл түшле, очлаеп килгән тар озын кара канатлы, сәнәк сыман аерылып торган койрыклы була. Әлеге кошның очышына карап, аны шаяра, уйный, кояш нурларында коена дип уйларга мөмкин. Чынлыкта исә ул бертуктаусыз «эшли» — бөҗәк тота.
Карлыгач иртә таңнан караңгыга кадәр һавада була, кайчагында гына тимерчыбыкка яки нечкә агач ботагына кунып ял итә.

### КЫЗЫК

Карлыгач җиргә бик сирәк төшә. Ул хәтта суны да очкан килеш кенә томшыгы белән чумырып ала.

Карлыгачлар югары очса — көн яхшыра, түбән очса — начарлана, диләр. Бу сынамыш дөрес, әмма эш карлыгачларда түгел, алар тота торган бөҗәкләрдә. Көн бозылыр алдыннан һава тагын да дымланып, бөҗәкләрнең канатлары бүртә, алар аска яки җиргә төшәләр. Шуңа күрә мондый вакытта кар-лыгач та астан оча.

# Карлыгач

*Габдулла Тукай*

Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын

Оя итте минем сөйгән карлыгачым:

Ул көн буе авызы белән балчык ташый,
Балчык белән матур итеп оя ясый.

Күп эшләде иренмичә; бара-бара
Чыгарды ул матур-матур балалар да.

Ачыксалар карлыгачның балалары,
Чебен-черки тотып кайта аналары.

# Козгын
# Ворон

Козгын чыпчыксыманнар арасында иң зур, иң ерткыч һәм дөньядагы иң акыллы кош санала.
Алар Төньяк Америка, Төньяк Африка, Үзәк һәм Төньяк Азия киңлекләрендә, Европаның барлык урыннарында таралган. Бу төр кошлар кешеләрдән читтәрәк яшәргә тырышалар. Шул ук вакытта авылга якын урыннарда һәм шәһәрдә яшәүче козгыннар да бар.
Безнең якларда гади козгыннар яши, сан ягыннан күп түгел. Алар утрак тормыш алып баралар. Урмандагы карт агачларга, шәһәрдә чиркәү манараларына яисә биек бина өсләренә оялыйлар. Нигездә, парлап яшиләр. Ашарга яраталар. Төп ризыклары — чүплектә казынып тапкан үләксәләр. Шул ук вакытта вак хайваннар, кошлар, балыклар һәм бөҗәкләр белән дә тукланалар.

# Кара карга
# Грач

Кара карга козгынга караганда кечерәк. Кап-кара төстә, ялтырап тора, бары зур томшыгы өстендә генә ак сызыгы бар.
Элек барлык кара каргалар да кышларга көньякка очып киткәннәр. Хәзер аларның кайберләре безнең якларда, кешеләр янында кышлый. Җылы яклардан кайтучылары яз башында (март аенда), әле җирдә кар ятканда ук кайта. Шуңа күрә дә аларны «яз хәбәрчеләре» дип атыйлар.
Ул оясын агач башында ясый һәм шунда бала чыгара. Кара карга — иң файдалы кошларның берсе. Алар май коңгызларын, аларның личинкаларын, саранчаларны, кыр тыч-каннарын юк итәләр.

# Карга әфәнде

*Айдар Җамалиев*

Кап-кара ялтыравык каурый. –
Кыр тычканы, саранча,
Ул якынлашкач, калмый.
Томшыгында бар бер ак сызык,
Өп-өр-яңа френч кигән,
Атлап йөреше кызык.

«Әфәнде» чакырганга, яз да ашыга.

Исемен кем дә белә,
Бу — кара карга!

# Кара карга

*Нури Арсланов*

| | |
|---|---|
| Аны яз кошы диләр,<br>Еракта кышлый, диләр.<br>Беренче булып кайта да<br>Ул куа кышны, диләр.<br>Кара карга кар куа, –<br>Кара җирләр калкуга,<br>Сабанчы белән бергә<br>Төшә дә җылы җиргә<br>Ул атлап йөри ипләп,<br>Төрле кортларны чүпләп. | Уйный кояш нурлары –<br>Ялтырый каурыйлары.<br>Кояш та кала күреп:<br>Кем оя салган үреп? –<br>Талда кара каргаларның<br>Йортлары бүрек-бүрек.<br>И матур шушы чаклар!<br>Бик кадерле кунаклар –<br>Каргалар кайтты диеп<br>Гөр килә ерганаклар. |

# Тургай
# Жаворонок

Тургай — безнең якларга яз көне кара каргалардан соң (апрель аенда) килә торган күчмә кошларның берсе. Ул басу-кырларда, көтүлекләрдә, болыннарда яши. Карасу таплы сары төстә булуы аңа чит-ят күзләрдән яшеренергә ярдәм итә. Дошманыннан яшерер өчен, оясын үлән зур булып үскән җирдә ясый. Җәй буена ике мәртәбә бала чыгара. Ояда 4—6 күкәй була. Кошчыклар бик тиз үсә, инде 9—10 көннән ояны ташлап та китәләр. Күп тургайлар икешәр оя ясый.

Көз көне тургайлар, төркемнәргә берләшеп, басу-кырларга очып китәләр. Салкын көннәр башлангач, янә җылы якларга күченәләр.

Әлеге кошлар басу-кырлардан зарарлы бөҗәкләрне дә чүплиләр, чүп үләне орлыкларын ашап та файда китерәләр.

Тургайларның кабатланмас сайравы, гаҗәеп матур җырлары турында шигырьләр язылган, көйләр чыгарылган.

### КЫЗЫК

Тургай очкан вакытта сайрый. Көчле җил яисә салкын бул-ганда гына, җиргә төшеп сайрарга мөмкин.

# Урман тургае

*Гарәфи Хәсәнов*

Санап бетергесез канатлы җырчылар яши безнең якларда. Иртә язда урман-кырларга чыксаң, әйләнеп кайтасың килми. Сайрар баркылдыкны гына тыңлап кара. Күпме тыңласаң да туйдырмый. Таңда кояшны җыр белән каршылый, кичен җыр белән озатып кала. Аңа бүтән кошлар кушыла. Әйтерсең җыр ярышы ачканнар, баркылдык әйтерсең бу хорда башлап җырлаучы. Ашыкмыйча, тәмен белеп кенә башкара ул җы-рын. Аның белән ярышса, тик урман тургае гына ярышыр.
Урман тургае бик иртә кайта, сабан тургаеннан бер дә калышмый. Кыш әле калын тунын салмаган, ә тургай, яз киләсен тоеп, чишмәдәй челтери. Аңа кушылып, урман ешлыгыннан башка тургайлар аваз бирә. Урман тургае хәтта сайрар баркылдыкны да уздыра. Төсе-кыяфәте сабан тургаена охшаш. Тик гәүдәгә аннан бераз кечерәк, ә башында коңгырт түбәтәе бар.
Җәйге төндә эткә урман тургаен агач башында күрә алмассың. Ул ак болытлар янына омтылыр, зәңгәр күктән табигатькә мәдхия җырлар. Чөнки җыр өчен көндез аның вакыты кал-мый. Көнозын әнкә дускаена балаларын тәрбияләр-гә булыша. Шуңа күрә күккә кояш баткач кына күтәрелә. Якты йолдызлар гүя аның җырыннан кабына, урман-күлләр-дәге камышлар әйтерсең лә аның моңына баш ия: «Лү-лү-лү... лү-йу-ли-ли...» — төн буе шушы җырын өзми-куймый суза ул. Гаҗәп йомшак, искиткеч саф тавышы тын урманда кош балаларына бәллү җыры булып яңгырый. Бу яктан ул мәшһүр сандугачка тартым.
Урман тургае җырлавыннан көзге салкында да туктамый. Туганнары — сабан тургайлары киткәч тә, безнең як урман-нарын ташла-мый, җырлый да җырлый. Күктә берзаман ап-ак кар бөртекләре оча башлый, бары шул чакта гына ул ерак сәяхәткә кузгала. Болытлы көзге күктә урман тургаеның моңлы җы-рын ишетсәң, гүзәл җырчының туган ил белән хушлашуы дип кабул ит.

# Сыерчык
# Скворец

Сыерчык — бик матур итеп сайрый торган күчмә кош. Ул туган якларында гөрләвек-ләр ага башлау белән күренә.
Беренчеләрдән булып, ата сыерчык кайта. Бу чорда аның җыры моңсурак була. Ә инде ана сыерчык кайткач, алар бергәләшеп илһамланып җырлыйлар. Сыерчык хәтта башка кош булып та җырлый ала. Сыерчык башкаруында карга тавышын да, карлыгач чәрелдәвен, колын кешнәвен һ. б. тавышларны да ишетергә мөмкин.
Алар агач куышларында, түбә астын-дагы уентыларда, яр карлыгачы ояларында яшиләр. Ә инде кешеләр ясап элгән оялар булса, шатланып туя алмыйлар. Ана сыерчык зәңгәрсу күкәй сала. Сыерчык балаларының авызлары зур, томшык читләре сары төстә була. Караңгы ояда аларны эти-әниләре шул сары томшыкларыннан таба. Бу чорда сыерчык концертлары туктап тора, чөнки аларның балаларын ашатасылары бар. Галимнәр фикеренчә, сыерчыклар балаларына һәр ике минут саен җим, күбесенчә бөҗәкләр китереп торалар икән.

**ҖАВАПСЫЗ ТАБЫШМАК**

Очып баручы сыерчык көтүе үзенең оешканлыгы белән күпләрне гаҗәпләндерә. Көтү эчендәге меңләгән сыерчык барысы берьюлы хәрәкәтләнә, мәтәлчек атып, очыш

хәрәкәтләрен үзгәртә. Әлеге кошларның мондый бердәм хәрәкәт тудыра алу мөмкинлекләрен бер галимнең дә аңлата алганы юк.

# Сыерчык

*Нәҗип Мадьяров*

Шатлыгы сыймый эченә,
Сайрый ул сузып-сузып.
Йә әйләнә бытбылдыкка,
Йә җырлый тургай булып.

Бака булып та бакылдый,
Тартар да була ала.
Кызылтүш кебек тә сайрый,
Канатын кага-кага.

Юкка сөенми, аңа бит
Бик ошый яңа оя.
Шуны ясап биргән өчен,
Ул безгә концерт куя.

# Сандугач
# Соловей

Сандугач җылы яклардан яз ахырында кайта. Аның сай-равын да май аенда гына ишетергә мөмкин. Сандугач — күренми торган һәм бик сак кош. Ул бары кичен, төнлә яисә таң атканда илһамланып сайраганда гына онытылып китә. Ләкин, караңгы булганлыктан, аны бу вакытта күреп бул-мый.
Ул торак йортларга якын урнаш-кан парк яисә бакчаларда яши. Июнь урталарында 4—5 бала чыгара. Бу вакытта сандугач концертлары тынып кала, алар, җырлауларын оны-тып, бала тәрбияләргә керешәләр: балаларына чебен, коңгыз, личинкалар ташып ашаталар.
Сандугач җиргә — оясына — бик саклык белән генә төшә. Өенең кайдалыгын белдермәс өчен, әле бер җиргә, әле икенче җиргә куна.
Сандугач кышларга Африкага оча.

## Атказанган сандугач

*Роберт Миңнуллин*

Ул сандугач — дус сандугач!
Көн дә бездә кунакта.
Минем өчен җырлар җырлый
Бакчабызда — куакта.

Сайрагач ул матур итеп,
Бик күңелле миңа да.
«Атказанган сандугач» дип
Исем бирдем мин аңа.

Аның ничек сайраганын
Тыңлатыр идем сезгә.
Сез үзегез дә ышаныр
Идегез минем сүзгә.

Ләкин җырчы сандугачым
Өйдә түгел — ул әле
Җылы якка гастрольләргә
Китеп барды шул әле!

# Миләш чыпчыгы Дрозд-рябинник

Миләш чыпчыгы — җырчы кош. Алар иртән кояш чык-канда да, көндез дә, бер-берләреннән уздырырга тырышып, гаҗәп матур җырларын сузалар. Юкка гына аларны урман сандугачы димиләр.
Ул — шактый зур, сыерчык чамасындагы кош. Аркасы кара, ә соры тимгелле түше ачыграк төстә.
Миләш чыпчыгы безнең якларга апрель урталарында кай-та. Оясын корыган яфрак, үлән, нечкә чыбыклардан зур итеп ясый. Ул оясы янына кеше килүдән курка. Нәрсәдер сизсә, берничә көн утырган оясын ташлап та китәргә мөмкин.
Балаларын бөҗәкләр, кайвакыт урман җиләкләре белән дә туендыра. Аларны көнгә 150—200 тапкыр ашата.
**КЫЗЫК**

Миләш чыпчыкларының, балаларын саклау өчен, батырлыклар күрсәтүе билгеле. Бер натуралист мондый хәлне күзәтә: үлән арасындагы кош баласын бер эт тотмакчы була. Кошчык аның борын төбеннән очып китәргә өлгерә. Эт кош артыннан ыргыла. Моны күргән ана кош, каты итеп кычкырып, эт артыннан ташлана. Эт, кечкенә кошчыкны калдырып, зурысын куа башлый. Кыю ана кош качып өлгерә. Шулай итеп баласын саклап кала.

# Миләш чыпчыгы

*Рафис Корбан*

Нигә миләш чыпчыгы дип
Атаганнардыр үзен?
Миләш түгел, баласына
Бөҗәк ташый көнозын.
Үзе миләш агачына

Хәтта оя да кормый.
Чыпчык түгел, ә шулай да
Чыпчык кебек чыркылдый.

# Песнәк
# Синица

Песнәкләрне авылда да, шәһәрдә дә очратырга мөмкин. Көз һәм кыш көннәрендә алар җимлекләргә бик еш килә. Ә җәй көне бөтенләй диярлек күренмиләр. Бу чорда алар балаларына ризык эзләү белән мәшгуль була.
Кыш көне песнәкләрне ашатырга, җимлекләр ясарга, оялар элеп куярга кирәк. Салкын вакытта алар орлык белән тукланалар, сөяктә калган итне дә бик яратып чукыйлар, терлек маен ашыйлар.
Песнәкләрнең токымы бик зур: **зур песнәк**, **зәңгәр песнәк**, **озын койрыклы песнәк**, **ак песнәк**, **көрән башлы песнәк**, **бүрекле песнәк**. Зур песнәк башка песнәкләрдән яшькелт-сары аркасы һәм ачык сары төстәге түше белән аерылып тора. Түшенең уртасында — кара юл, башында кара түбәтәй була. Зәңгәр песнәкнең түше генә сары, аркасы, канатлары, койрыгы күк кебек зәңгәр төстә. Озын койрыклы песнәк — тыныч, шыпырт кош. Зур түгел, үзе ап-ак, аркасы гына кара. Койрыгы чуар, озын саплы кашыкка охшаган. Ак песнәкнең бүреге, аркасы, койрыгы, канатлары — күк, башка җире ак төстә. Кара песнәкне нечкә ботакларда акробатик күнегүләр ясый торган кош дип әйтергә мөмкин. Ул ризыкны ботакка баштүбән эленеп эзли. Аның өске ягы һәм тамак асты кап-кара, яңаклары һәм түше ак. Муен өстендә ак табы бар. Көрән башлы песнәк кара песнәктән муен өстендә ак табы булмау белән генә аерылып тора. Ул усак һәм каен орлыкларын ярата. Бүрекле песнәкнең башында кикрик сыман каурые була.

### МОНЫ БЕЛЕРГӘ КИРӘК

Песнәк тозлы терлек маен ашаса үләргә мөмкин.

# Песнәк

*Йолдыз Шәрәпова*

«Бигрәк суык кышларын,
Белмим, ничек кышлармын?
Азык табу бик кыен,
Җан асрау — бар уем», –
Яныма очып килде,
Бер песнәк шулай диде.
Ачыга икән бит песнәк,
Тик утырыйк без нишләп?!
Өйдәге бер тартмадан
Әти җимлек ясады.

Тары, көнбагыш салдык,
Песнәк тәмләп ашады.
Сыйлансын әйдә песнәк,
Арыгандыр җәй эшләп.
Күп кортларны юк итте,
Җимлектә безнең рәхәт.

# Чәүкә
# Галка

Чәүкә — шәһәр һәм авыллар-да очрый торган иң гадәти кош. Алар-ның күпчелеге кыш көне җылы як-ларга китми. Ояларын өй кыекларында, мич морҗаларында, манара баш-ларында, агач куышларында ясый.
Ул каргадан кечкенәрәк, төтен сыман кара-көрән төстә, көлсу-көрән башлыклы була. Апрель башында 4—5 бала чыгара. Алар-ны бөҗәк-ләр һәм күбәләк кортлары белән тук-ландыра. Көзгә кадәр чәүкәләр болын-нар-да, басуларда, көтүлекләрдә гаять күп бөҗәкләрне юк итәләр. Ә инде көзен, бөҗәкләр беткәч, бушаган иген басуларында орлык чүплиләр. Шәһәр җирендә яши торганнары, төрле ризык калдыкларын, чүп-чарларны ашап, «шәһәр санитарлары» вазифасын да баш-каралар.

## Файдалы чәүкәләр

*Айдар Җамалиев*

Апрельдә һәрчак
Тормыш җанлана,
Тынлык югала:
Безнең чәүкәләр
Оялар кора,
Чыгара бала.

Бәләкәчләргә
Көл-көрән кошлар
Корт-бөҗәк ташый.
«Пи-пи-пи, рәхмәт!» –
Кошчыклар тәмләп,
Яратып ашый.

Чәүкәләр, үскәч,
Гаскәрләр булып,
Кырларны яулый:
Бөҗәкләр ашый.
Көзен басуда
Әрәмгә, тиккә
Бөртекләр калмый.

# Күке
# Кукушка

Күке — урман кошы. Аны башка исем белән «кәккүк» дип тә йөртәләр. Урманда булган һәр кешенең күке күкелдәвен ишеткәне бардыр, мөгаен.
Күкеләрнең күбесе йомыркаларын башка кошларның ояларына сала. Бары йомыркаларның төсләре генә туры килсен. Күкенең карчыганыкы кебек сырлы күкрәген күргә, кошлар, куркып, ояларыннан очып китәләр. Күкегә шул гына кирәк тә. Ул шул арада әлеге кошның оясына йомыркасын салып та куя. Аларның чит ояга елына 25 кә кадәр йомырка салулары билгеле.

**КЫЗЫК**

Күке баласы, йомыркадан чыгуга, үзе белән бергә дөньяга килгән кош балаларын оядан кысрыклап чыгара баш-лый. Ни өчен дисезме? Чөнки күке бик күп ашый. Ояда берүзе калса, ризык күкегә генә эләгә.
Күке — иң файдалы кошларның берсе. Алар башка кошлар ашамый торган зарарлы бөҗәкләрне дә күпләп юк итәләр.

# Кәккүк

*Әхмәт Исхак*

Якты яз җиткәч,
Яшел урманнан
Кәккүк тавышы
Яңгырый һаман:
«Кәккүк! Кәккүк!
Кәккүк! Кәккүк!»
Башка кошлар күк,
Ул оя кормый,
Үстерми бала,
Җырлый да җырлый:
«Кәккүк! Кәккүк!
Кәккүк! Кәккүк!»
Ул чит ояга
Күкәйләр салган,
Эзли шуларны,
Кычкырып һаман:
«Кәккүк! Кәккүк!
Кәккүк! Кәккүк!»

# Күгәрчен
# Голубь

Күгәрченнәр борынгы заманнарда тауларда яшәгән. Ә хәзер аларның күбесе кешеләр янында гомер итә.
Күгәрченнәрнең төрләре бик күп: **декоратив күгәрчен, почта күгәрчене, йорт күгәрчене, кыр-гый күгәрчен** һ. б.
Без күбрәк күк күгәрченне беләбез. Аның канатлары күк-сел төстә була. Муены белән күкрәгендә әле яшел төс, әле ал төс чагылып китә. Тәпиләре кып-кызыл. Ул, вак-вак атлап, яңа яуган карда бормалы, кәкре-бөкре эзләр калдырып йөри.
Күгәрченнәр февраль аенда ук гөрләргә, парларын эзләргә керешәләр. Әле бер урында әйләнеп, әле койрык җәеп, иелеп-бөгелеп, «кәләшләр» каршында бииләр.

**КЫЗЫК**

Күгәрчен башка кошлардан юлны тиз табуы белән аерылып тора. Моннан күп йөз еллар элек — радио, телеграф, поезд, самолётлар булмаган заманнарда — хатларны күгәрчен ташыган.
Күгәрчен дуслык һәм тынычлык символын аңлата.

# Күгәрчен

*Нури Арсланов*

Бер кошка кызыгамын –
Тәпие кызыл аның.
Атлаган саен баш ия –
Гадәте кызык аның.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Бигрәк чибәр, кемдер бу?

Ак та була күгәрчен,
Күк тә була күгәрчен.
Уйный кояш нурларында –
Күктә була күгәрчен.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Бигрәк чибәр, кемдер бу?

Күк күгәрчен күк була,
Төскә һава күк була.
Шуңа күрә, күрәсең,
Аның аты — күгәрчен.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Бигрәк житез, өлгер бу.

Күгәрчен, гөрлә, гөрлә!

Өй түбәсендә — түрдә.
Күгәрчен тыныч көн күрә
Кешеләр белән бергә.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Гөрли торган көндер бу.

# Торна
# Журавль

Торна — озын аяклы һәм озын муенлы, матур гәүдәле, нәфис хәрәкәтле күчмә кош. Ул эре кошлардан санала: биеклеге 90—155 сантиметр, авырлыгы 2—11 килограмм, канатларының колачы 150—240 сантиметр. Башы кечкенә, томшыгы туры һәм очлы. Аның тавышы сагышлы да, шул ук вакытта тантаналы һәм аһәңле дә.

Бу кош мүк, мүк җиләге яисә тәбәнәк чыршы белән капланган урман сазлыгында яши. Безнең як-ларга кайткач, оя ясамый, иске оясын эзләп табып, шунда урнаша. Елга 2—3 бала чыгара һәм аларны ояда бик озак ашата.

Ул үсемлек орлыклары, җиләк, балыклар белән тук-лана.

Торна — бик сак кош. Гадәттә картрак торна сакта тора һәм кеше килүен ерактан ук күреп ала. Шунда ук кычкырып хәбәр дә бирә. Шулай да бу кошларның язгы уенна-рын ерактан гына булса да күрергә мөмкин.

### КЫЗЫК

Торна, башка кошлардан аермалы буларак, агачка кунмый.

# Торналар килде

*Гамил Афзал*

Кар сулары аккан чакта,
Тезелешеп, җылы яктан
Торналар кайтты безгә,
Канатлар какты безгә.

Кычкырдылар: «Торыйк-торыйк,
Сезнең белән дуслар булыйк,
Көзгә чаклы бергә торыйк!
Торыйк-торыйк, торыйк-торыйк!»

# Торна

*Гарәфи Хәсәнов*

Яз инде бусаганы атлый берзаман, шунда биектә тансык авазлар да яңгырый:
– Тор-рыйк!.. Тор-рыйк!..

Һи, без көткән торналар кайта икән ич! Алар, соклангыч бер өчпочмак ясап, төркем-төркем булып кайталар. Һәркайсыбыз аларны шатланып каршы ала:
– Торналар кайта, торналар!
Инде чын мәгънәсендә язны тою хисе күңелләргә бер-төр-ле ләззәт бирә.
Алар яз саен бер үк сазларына кайталар. Саз да зур, кошлар көтүе дә зур. Ләкин ник берсе торган түмгәккәен бутасын! Кайта да түмгәккәен барлап оча әткә кош. Үзе биектә озын канатларын җилпи, үзе өзлексез «тор-рыйк» сүзен кабатлый. Әле янында сайлаганы оча, ул да, «тор-рыйк» дип, аның сүзен кабатлый. Чөнки торналар монда да, җылы якта да парлашып яшиләр. Алар сазлык янын-дагы тигезрәк бер урынны сайлап, уен мәйданы итәләр. Сүз берләшкән кебек, шунда җыелалар. Башта басулар гизеп тамакларын ялгыйлар, ә кичен шунда очып төшәләр. Төшеп тә җитәләр, ни арада зур бер түгәрәк тә ясыйлар. Шуннан инде, ымсынып, чын мәгънәсендә дәртле биюләрен башлап җибәрәләр: озын аяклар да тик тормый, киң канатлар да тик тормый. Әле кайберсе җирдән таяк-мазар алгалый. Аны томшыгы белән өскә чөеп-чөеп җибәрә һәм муенын сузып тотып алырга да өл-герә. Нинди генә мәзәк хәрәкәтләр ясамый алар?! Кошларның дәртле уен-нарын бүлмәгәйләре дип, бер карт кош бөтен тирә-юньне күзәтә. Торналар, димәк, сизгер сакчы да куялар.
Саз тора-бара яшел үлән белән каплана, шунда түмгәктә оя кору эшләре дә башлана. Әйе, һәр пар үз түмгәгендә тирән оясын әмәлли. Эш беткәч, бер пар күкәен дә сала әнкә кош. Күкәй өстендә утырырга әткә дускае да булыша. Әмма аның төп эше — тирә-юньне күзәтү. Әткә кошны сугыш чукмары дип әйтерсең, хәтта дүрт аяклыларны тәүбә иттерергә дә күп сорамый. Ә кеше килсә — хәбәр бирү белән чикләнә. Әнкә кош шундук оясыннан шуыша, читкә китеп, аягүрә торып баса. Хәйләли инде, хәйләли! Бу тирәдә бернинди оя да, ул ояда бернинди күкәй дә юк, янәсе...
Үз сазы һәрбер торнага да кадерле, ул — аның туган йорты. Шунда дәү үсәр ул, зур бер төркемгә дә кушылыр. Ул да, киткәндә, «тор-рыйк» дип әйтер дә шул өне белән күңел кылын тибрәтеп җибәрер.

# Тукран
# Дятел

Тукраннарның 380 ләп төре бар. Аларның гәүдәләре зур түгел. Әйтик, **зур чуар тукранның** авырлыгы 100 грамм, гәүдә озынлыгы якынча 23—26 сантиметр.
Тукран — бик файдалы кош. Ул агачтагы корткыч бөҗәк-ләрне юк итә, агачның гомерен саклый. Шуңа күрә аны урман докторы дип йөр-тәләр. Әлеге кош, каты койрыгы белән агач кәүсәсенә терәлеп, аңа көчле тыр-наклары белән ябыша. Аннары, томшыгы белән агачны тук-тук чукып, бөҗәкне эзләп таба һәм теле белән эләк-тереп ала да ашый. Шулай итеп үзе дә туклана, урманга да файда китерә.
Безнең урманнарда тукранның берничә төре яши: **кара тукран**; **яшел тукран**; **өч бармаклы тукран**; **зур, кечкенә** һәм **уртача зурлыктагы чуар тукран**. Зур чуар тукран башкала-рына караганда ешрак очрый.
Тукраннар барысы да агач куышында оялый.

**КЫЗЫК**

Тукраннар бер-берләрен томшыклары белән агачка бәр-гән тавышларыннан (тукылдауларыннан) таныйлар. Шуңа күрә тукран үзенең күршесен беркайчан да бутамый, ә чакырылмаган кунакның тукылдаган тавышына шунда ук колагын торгыза.

# Урман докторы

*Мәрзия Фәйзуллина*

Тукран һәр агачны
Тук-тук-тук сугып карый,
Көчле һәм очлы борыны
Шундый зур эшкә ярый.

Агач кимергән кортларны
Эзләп, чукып бетерә.
Урман докторы булып, ул
Бик күп файда китерә.

# Акчарлак
# Чайка

Акчарлак су тирәсендә яши һәм балык белән туклана. Әмма ул моның белән табигатькә зур зарар китерми, чөнки беренче чиратта авыру һәм үлгән балыкларны ашый. Шуның белән авыруларны таратмаска ярдәм итә.
Ул бик яхшы оча һәм бик әйбәт йөзә, хәтта су өстендә йоклый да. Җир өстендә дә менә дигән итеп йөри.
Акчарлаклар, оя ясар өчен, төркем-төркем булып, бер урынга җыелалар. Ояларына 1—4 йомырка салалар. Аларның балалары бик тиз мөс-тәкыйль яши башлый, бер атнадан инде кыю рәвештә суга керәләр. Әмма әле шуннан соң да аларга азыкны әти-әниләре ташый.

### КЫЗЫК

АКШның Солт-Лейк-Сити шәһәрендә гадәти бул-маган һәйкәл тора: биек гранит колоннаның башына глобус куелган, аның өстенә ике кош ясалган. Бу — анда килеп чыккан хисапсыз күп саранчаларны бетереп, кешеләрне ачлыктан коткарып калган акчарлаклар хөрмәтенә салынган һәйкәл.

# Акчарлак

*Йолдыз Шәрәпова*

Көймәбез артыннан бер кош

Ияреп очты, калмады.
Курыкмыйча якын килде,
Хәтта тотып алмалы.

Бер дә бездән калмады,
Белмим, ничек армады.
Балыкны да оста тотты,
Булмаса да кармагы.

Озак озатып барды,
Канатын кагып алды.
Күрәсең, ул шулай безгә
Ак юллар теләп калды.

Ул үзе дә ап-ак бит,
Куйган кебек акшарлап.
Елгаларның яме ул
Ак теләкле акчарлак.

# Ләкләк
# Аист

Ләкләк үзенең зур оясын авыл өе түбәсендә чыбык-чабык һәм ботаклардан ясый. Ләкләк оялаган йорт бәхет-ле нигез дип санала, шуңа күрә әлеге йортның хуҗасы аның тынычлыгын бозмаска тырыша.
Ләкләк — күчмә кош. Ул нигезен беркайчан да бутамый, яз саен шул оясына очып кайта. Елына 3—5 бәбкә чыгара. Бәбкәләр ата-аналары алып кайткан бака, тыч-кан, кәлтә яисә төрле бөҗәкләр белән туклана. Көзгә таба алар зур кош булып үсеп җитәләр һәм көньякка очып китәләр.

### КЫЗЫК

Ләкләк — тавышсыз кош. Алар бер-берсе белән том-шыкларын шыкырдатып «сөйләшәләр».

# Ләкләк

*Ленар Шәех*

Очып йөри ләкләк
Зәңгәр күктән... шәпләп:
«Бака, эләк, эләк –
Минем бөтен теләк».

Ә сазлыкта бака –

Бака-ка-ка-ка-ка
Бер түмгәктә ята,
Сазлыкны болгата:
«Мин — иң көчле бака,
Бака-ка-ка-ка-ка!..»

Очып барган ләкләк
Килеп төшә шәпләп
Һәм баканы каба.
Оясына таба
Очып китә ләкләк,
Канат кагып... шәпләп.

# Көртлек
# Тетерев

Көртлек оясын җирдә дә, агач башында да ясарга мөмкин, һәм ул үзе дөньяга килгән урыннан еракка очмый. Буранлы кышларда кичен, караңгы төшкәч, агач башыннан кар көр-тенә атылып төшеп, шунда төн куна.

Көртлекнең канаты кыска, киң, аяклары тиз йөгерү өчен җайлашкан, томшыгы шулай ук кыска, юан, бераз кәкре була.

Ул май ахырында — июнь башында бала чыгара. Йо-мыр-каларын җирдәге чокырларга сала һәм шунда мүк, вак чыбык-чабык, кош каурые ташый. Өч атнадан нәни кошчыклар дөньяга килә. Яңа туган кошчыклар, кип-шенеп өлгерүгә, әниләре артыннан калмыйлар, озакламый үзләре дә чебен, кырмыска, җиләк белән туклана башлыйлар. Аларны ана-лары йөртә, азык табарга, хәвеф-хәтәр бул-ганда, үлән арасына яшеренергә өйрәтә.

Көртлекнең яраткан ризыклары — төрле җиләкләр, үлән орлыклары, агач бөреләре, ылыслар, эрбет чик-ләвеге.

**БЕЛӘСЕҢМЕ?**

Әлеге кошлар эссе көннәрдә, бөҗәкләрдән котылу өчен, комда коеныргa яраталар.

Ана көртлек караңгы-коңгырт юллы җирән-чуар төстә булса, ата көртлек сумаладай кап-кара, күксел ялтыравыклы, кызыл кашлы, кара томшыклы, канат аслары ак була.

# Көрткә чумган көртлек

*Ленар Шәех*

Биек агач башында
Утырган кара көртлек
Һәм эрбет чикләвеген
Тутырган кара көртлек

Иң тирән кесәсенә...

Ботактан кар ишелгән.
Чикләвектән тулган кесә
Тишелепме-тишелгән.

Эрбет чикләвекләре
Кар өстенә чәчелгән.
Ерак офык кояшны
Куенына яшергән.

Караңгылык эчендә
Калган, ди, кара көртлек.
Кардан чикләвек эзләп
Арган, ди, кара көртлек.

Бик озак уйламаган,
Тирән көрткә чумган, ди.
Шулай итеп бу көртлек
Көрт эчендә кунган, ди.

# Көртлек

*Гарәфи Хәсәнов*

Әле кайчан гына яшел диңгез булып чайкалган тугай ап-ак карга күмелде. Тугайның бер очы каенсарга барып тоташа, ә ул каенсарны, икегә ярып, чана юлы уза. Әнә шул юлдан печәнгә дип килгәч, эшли башларга һич ашыкмыйсың, әйләнә-тирәгә күз саласың. Шул чагында синең игътибарыңны ап-ак каенсарга бөрчек-бөрчек булып төшкән сәер койрыклы чем-кара кошлар җәлеп итә. Һәр койрыкның уртасында тирән уентык булып, як-якта ике очы чорналып куелганга, елмаеп, аңа «мыеккойрык» дип әйтәсең. Күрәсе, күзәтәсе килү хисе җиңгәнгә, каенсарның эченәрәк керәсең. Кошларның ник берсе кунган ботагыннан купсын да ник берсе урман түренә җилпенсен...

Биредә кошлар ашаган азыкларын сеңдерәләр. Гадәттә, көнозын ешлыкта булалар, көнозын каен бөреләрен бүсәләр. Бары көн уртасында урман авызына чыгалар: үзләренчә кояш-та кызыналар. Ә кичен йокы симертүне карый бу кошлар. Биек көрт — менә нәрсә хуш килә көртлекнең күңеленә! Һәрбер кош утырган ботагыннан шунда атыла. Атыла, тирән карга күмелә. Кар эченнән күпме ара үтә дә, төн тикле төнне туңмый гына үткәрә. Көннәре шулай тәгәрәпме-тәгәри. Һа-ман бер үк төрле, һаман үзгәрешсез тәгәри. Менә берзаман көннәр озынаеп куя да салкын кыш китәр якка күз сала. Кояш тора-бара авыз йома белми елмая. Кояш агай нурга бай! Кошларга инде бүтән берни кирәкми. Ашауларын ук оныта-лар көртлекләр. Инде ничәмә-ничә тапкыр урман авызына оча-лар. Чыгалар, озаклап утыралар. Салкын кышның туны тишелгәч, җыр да яңгырата башлыйлар. Җыр белән чиксез шатлыкларын әйтәләр. Күгәрчендәй гөлдерәп тә күрсәтәләр. Тургайдай көмеш тавыш белән түрелдиләр. Күктә биектә сабан тургайлары челтери, җирдә якты гөрләвекләр челтери... Шул ике өнгә кушыла да көртлекләр.

Ә тора-бара шундый вакыт килә: карт көртлек, көтү башы, иртәрәк уяна. Таң атканчы ук карны тишеп чыга ул. Чыгу белән, урман авызына ашкына. Андагы биек каен ботагына утыра, шуннан дәртле гөлдерәвен башлап җибәрә. Әле, җырын бүлеп: «Чуфф-фыш!» — дип тә кычкыра. Аны, син күр дә мин күр, бүтән көртлекләр дә

кабатлый. Алар ни ара сирәк каеннарга чыкканнар, ни ара башлыкларының дәртле чуфылдавын «отканнар». Чуфылдау, гөлдерәү — хәзер шул ике аваз ишетелеп тора урманда. Кызып һәм берсе икенчесен уздырып, урман яңгырата көртлекләр.
Көннәрдән бер көнне көтү башы анысын да азсына, яңа һөнәр өйрәтергә ашкына. Ботакта килеш ике канатын да киң ача, ашыкмый гына агач төбенә очып төшә, пыялага әйләнгән кар өстеннән батмый гына тип-тигез ачыклыкка йөгерә. Ә ул «туй урыны», «уен мәйданы» дип атала. Һәр язны бер үк җирдә була да, һәр язны җим эзләп күчеп киткән күпме көртлекне кайтара. Алар көз һәм кыш ерак урманнарда булалар, бары яз килгәч, «Сабан туена» дип кайталар. Көтү шул рәвешле ике-ләтә артып куя бу чакта. Димәк, карт көртлек иске көтүне дә сәлам-ли һәм яшьләрне дә алып килә мәйданга. Әйләнә дә тул-гана... Көрәш батыры диярсең үзен: муены көянтә булып аска таба бөгелгән, башы алга караган, ә кашлар ут яна. Ә  инде чолгый-койрыгына күз салсаң, биниһая зур җилпәвечкә охшаган. Җилпәвеч кебек, өскә таратылып ташланган. Моңа канаты белән карны сыдыруын өстәсәң... «Батырга кем чыга?»  — бар кыяфәте шуны әйтә кебек тоела. Әле, чыннан да, бүтән көртлек төшә дә, көч сынашырга моның каршына килеп туктала. Монысы да муен бөгеп туктала. Баш алга караган, ә кашлар — ут яна. Канатлар каты карны сыдыра. Әле, җитмәсә, өскә сикергәләп тә куя. Алар күзгә-күз карашып бераз вакыт торалар. Әйтерсең түземлекләрен сыныйлар бу кошлар. Берсе, ниһаять, читкә китәр дигәндә... Көндәшләр кинәт әнкә кошны искәрәләр, аның бер читтә чемченүен күрәләр. Әйе, җим тап-кан кебек, томшык төртеп-төртеп ала әнкә кош. Менә шул инде гайрәтләндерү дип әйткәнең. Үзе төскә дә, гәүдәгә дә күп калыш, ә үзе дәрт өстәп җибәрә. Томшык һәм канат белән ике зур кош берсе икенчесен тукмакларга тотына. Тукмаклый, кара каурыйларын очыра. Кем көчле — батыр булып шул кала. Батырга әнкә кош та күз сала, хәтта аның артыннан ук иярә. Көчсез кош каурый «санау» белән чикләнә. Анда бер пары, монда икенчесе «көрәшә»... Ничә көн, ничә атна дәвам итә мондый хәл. Бары май ишек ачкач, төрлесе төрле якка тарала. Әткә кош, качып, каурый-йонын яңарта, әнкә кош җирдә ишле күкәйләрдә утыра. Аның өч атнадан соң нәни чебиләре туа.
Алар күкәйдән, сүз берләшкәндәй, бер үк көнне, бер үк сәгатьтә чыгалар. Һәм, чыгу белән, урман эченәрәк посалар. Анда аулак та, җиләкнең дә төрлесе бар. Әниләре янында җил-яңгыр тими үсә чебиләр. Төнне бары җирдә генә үткәрәләр, ләкин һәрвакыт әнкә көртлек янында: аның җылы һәм киң канаты астына сыенып, җимне дә бары әниләре күрсәткәч  кенә чүплиләр. Ул, үзе ашамыйча, әле кызыл җиләк, әле бөҗәк күрсәтә. Шулай яшь кошчыкларын җим табу-тану гыйлеменә өйрәтә. Ә инде атна-ун көн үткәч... Алар шул кыска арада танымаслык булып үзгәрә. Канатлары тәмам ныгып җитә, агач ботагына күтәреләләр. Хәзер инде төнне шунда үткәрә кошчыклар. Хәвефсез җирдә, әмма әниләре янында. Ә бер ай үткәч, ерак араларга очалар.

**Файдаланылган әдәбият**


Кем ул. Нәрсә ул : кече яшьтәге мәктәп балалары өчен  : 3 томда ; [рус тел. тәрж].  — Казан : Татар. кит. нәшр., 1983, 1985, 1987.
Мир и человек : географический атлас. — Москва, 1988.
Энциклопедический словарь юного натуралиста : для среднего и старшего школьного возраста [сост. : В. К. Ра-хилин, А. Г. Рогожкин]. — 2-е изд., доп. и перераб., — М. : Педагогика-Пресс, 1996.
*Вахтин В. Г., Вахтина Г. А.* Татарстан: в объективе живая природа = Татарстан: объективта җанлы табигать. — Казань : Татар. кн. изд-во, 1997.

*Ибраһимова Ф. Җ.* Табигать бизәкләре : башлангыч сыйныфлар өчен өстәмә уку китабы. — Казан : Мәгариф, 2002.
*Бровкина Е. Т., Сивоглазов В. И.* Птицы леса. — М. : Дрофа, 2006.
*Школьник Ю. К.* Птицы : полная энциклопедия. — М. : Эксмо, 2007.
*Латюшин В. В.* Хайваннар : татар урта гомуми белем бирү мәкт. 7 нче с-фы өчен д-лек / В. В. Латюшин, В. А. Шапкин; [русчадан Г. С. Хафизова тәрҗ.]. — Казан : Мәгариф, 2009.

Учебное издание

Серия «Путешествие в природу»

Для детей среднего и старшего школьного возраста

Автор серии и автор-составитель
**Шакирова** Талия Ривовна

**ПТИЦЫ**

Издание второе, дополненное

Казань. Татарское книжное издательство. 2013

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

«Табигатькә сәяхәт» сериясе

Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен

Серия авторы һәм автор-төзүчесе
**Шакирова** Талия Риво кызы

**КОШЛАР**

Тулыландырылган икенче басма

Мөхәррирләре *Т. Р. Шакирова, Э. Т. Кәлимуллина*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Л. И. Матвеева*
Корректоры *Г. Х. Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.02.2013.

Форматы 70×100$^{1}/_{16}$. Шартлы басма табагы 5,85.

Тиражы 4 000 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**

Казан, Декабристлар урамы, 2.

Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.

Казан, Декабристлар урамы, 2.

Татарстан китап нәшриятының күргәзмә-кибете. Тел.: (843) 519-45-13.

Казан, Бауман урамы, 29/11.

Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.

420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.